ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2025 с.Старое Дрожжаное №560

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2020 N 1245, 26.07.2021 N 645, 30.10.2021 N 1030, 19.02.2022 N 141, 15.06.2022 N 566, 22.09.2022 N 1027, 24.05.2024 № 361, 12.09.2024 № 779, 23.04.2025 № 260, 22.09.2025 № 721 ред.) «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарының гамәлдә булуын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларына кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән хезмәт шартларының җитди үзгәрүе турында хәбәр итәргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 15 маендагы 156 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Р.И. Мөхәммәтҗанов